**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ
РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

от 11.02.2014 №92-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2013 елның 10 июлендәге 385-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2013 елның 10 июлендәге 385-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.5 пунктының алты пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән ГТС өчен хокук билгели торган документлар күчермәсе;

1.2. 2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле дүртенче пунктча өстәргә:

4) Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан ГТС өчен хокуклар турында белешмәләр (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтендә).»;

1.3. 3.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә;

Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү турында – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә;

ГТС файдалануга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган белешмәләрне Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан бирү турында, – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә;

Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан ГТС буенча белешмәләр бирү турында – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында гаризалар. ».

2. Мәгълүмати геологик ресурслар һәм геологик тирәлекне мониторинглау бүлеге җитәкчесе В.Л.Полушинга Регламентны Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталының Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы субпорталында урнаштырырга.

3. Хокук бүлеге җитәкчесе В.А.Тронинга әлеге боерыкның дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны җир асты байлыкларыннан файдалану буенча министр урынбасары Т.М.Акчуринга йөкләргә.

Министр А.Г.Сидоров